# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Иске Салавыч авылы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 11 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең Иске Салавыч торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. «90% күләмендә ташлама билгеләнгән I группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннары, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләр, ялгыз яшәүче 80 яшьтэн өлкән кешеләрдән, торып укучы студентлардан, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны, контракт буенча хезмэт итучелэрне һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Салавыч авыл җирлегенең Иске Салавыч авылында яшәү урыны буенча теркәлгән , балигъ булган һәр гражданга 2024 нче елда үзарасалымны 600 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү:
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары ( тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау , карап тоту:

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Салавыч авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль , берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Балтач муниципаль районы
Салавыч авыл җирлеге башлыгы Р.К.Латипов